**ГЛАВА**
**БИКУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИККОЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Биккол ав. **КАРАР**

«11» июль 2022 ел №2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылында гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елның 22 июлендә 10 сәгать 00 минутка Биккол авылы, Мәктәп урамы, 15а йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегендәге Биккол авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Биккол авылында яшәүче гражданнар өчен тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Элегрәк расланган Халык Җыенына кертелгән сорауга үзгәрешләр кертү белән килешәсезме?:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылында халык җыены нәтиҗәләре турында 27.11.20021 ел, № 1 карарына
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылында халык җыены карарына (27.11.2021 ел), аны киләсе редакциядә раслап:

«2022 елда үзара салым кертүгә Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- янгын сүндерү техникасын урнаштыру өчен торак булмаган бинаны капиталь ремонтлау;

- Биккол авылында юллар салу өчен вак таш сатып алу;

- Биккол торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны кыш көне карап тоту.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биккол авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Әхмәтшина